ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**2020 елның 10 июне** **Чистай шәһәре** **№ 309**

Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының
2019 елның 25 декабрендәге
“Табиблар - торак шартларын яхшыртуга
мохтаҗ белгечләргә торак урынын наем (арендалау)
чыгымнарны компенсацияләү
тәртибен раслау турында”гы
709 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының “2019-2021 елларга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында медицина кадрларын беркетү һәм аларны торак белән тәэмин итү” муниципаль программасын раслау турында” гы 2019 елның 12 сентябрендәге 473 номерлы карарын гамәлгә ашыру максатларында «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль хокукый актларын туры китерү максатларында, Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 25 декабрендәге “Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ табиб-белгечләргә торак урынын наем (аренда) өчен түләү чыгымнарын компенсацияләү тәртибен раслау турында”гы 709 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- “20__ елның “__” _____(-нән/-нан) 20__ елның “__” ______(-нә/-на) кадәрге чорда табиб-белгечләргә торак урынын наем (арендалау) буенча чыгымнарны компенсацияләү турында белешмәләр” таблицасында “Түләү өчен компенсация түләү турында” гы 3-нче баганасын үз көчен югалткан дип танырга;
- “20__ елның “__” _____ (-нән/-нан) 20__ елның “__” ______(-на/нә) кадәрге чорда табиб-белгечләргә торак урынын наем (арендалау) буенча чыгымнарны компенсацияләү турында белешмәләр” таблицасында “Табиб-белгечне тәэмин итү өчен кирәкле торак урынның мәйданы” 9-нчы баганасын үз көчен югалткан дип танырга;
- “20__ елның “__” ______ (-нән/-нан) 20__ елның “__” ______ (-нә/-на) кадәрге чорда табиб-белгечләргә торак урынын наем (арендалау) буенча чыгымнарны компенсацияләү турында белешмәләр” таблицасында “Россия Хезмәт министрлыгы боерыгы нигезендә 1 кв. м торакны наем (арендалау) бәясе” 10-нчы баганасын үз көчен югалткан дип танырга;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Г.Ю. Задворновага йөкләргә.

Башкарма комитеты
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов